*Өчиле төп гомуми белем мәктәбе*

# Чишмә башы

*Сентябрь-2025*

## Хөрмәтле укытучылар,кадерле укучылар, әти-әниләр!

Яңа уку елы барыбызга да уңышлар алып килсен!

### Сентябрь аенда туган әдипләребез

6 – Шагыйрә, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Флёра Гыйззәтуллинага 90 яшь.
8 -Язучы, драматург, мөхәррир Мәхмүт Галәүнең тууына 135 ел (1886–1938).
9 –Язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Хәниф Хәйруллинның тууына 90 ел (1931–1998).
16 –Язучы Атилла Расихның тууына 105 ел (1916–1996).

19-Язучы Альбина Нурисламовага 45 яшь.
20 – Мәгърифәтче, драматург, археограф Габдрахман Ильясиның тууына 165 ел (1856–1895).
Язучы, тәрҗемәче Идрис Туктаровның тууына 125 ел (1896–1982).
Язучы, драматург, публицист Габдрахман Минскийның тууына 115 ел (1906–1983).




Изге телнең моңын, бар тылсымын;

Җир йөзендә ниләр барлыгын.

Ни өчен кич кояш батуын,

Якты йолдызларның балкуын.

Иксез-чиксез галәм серләрен.

Агач, үсемлекләрне, гөлләрне;

Африканың кайнар чүлләрен.

Жырчы чишмәләрне, җилләрне,

Диңгез, океаннарны, күлләрне;

Тагын бик күп әллә ниләрне

Мәктәбебез безгә өйрәтер.

# Сентябрь ае турында укучыларыбыз

Сентябрь – җәйге ай түгел, көзге ай дип тә атарга авыр. Көз – ул яңгырлар, эсселек, туңдыру. Сентябрь аенда көндез кояш яхшы кыздыра. Әмма кояш горизонтка кергәч, табигать көз турында искә төшерә. Шунда ук салкыная, чөнки җир кыска көзге көн аркасында җылына алмый. Иртәнге сәгатьләрдә дә салкын белән бөрки.

Агачлар яфракларын теләмичән генә алыштыралар. Тик көннән-көн агачларда чуар яфраклар арта бара. Табигать үзгәрә, яшел буяулар салмак кына сары, көрән, кызыл төсләргә алышына. Матурлык төсләрнең табигый төрлелеге белән таң калдыра.

Сентябрь аенда барысы да әбиләр чуагын көтә. Бу чорда җылы, һавада пәрәвезләр оча. Сентябрь урманнары гөмбә белән үзләрен җәлеп итә.

Кошлар күпләп җылы якларга очарга әзерләнә. Сентябрьнең икенче яртысында еш-рак яңгырлар ява һәм суыта.



Сентябрь ае – уңыш җыю, хуҗалык эшләрен башкару, мәктәп укучылары һәм студентлар өчен яңа уку елы башланган чор. Әлегә көннәр матур торса да, тиздән яңгырлы, җилле көннәр, ә аның артыннан кыш фасылы да килеп җитәр.

Сентябрь чын мәгънәсендә алтын ай ул. Ләкин бу табигатьнең алтын-сары төскә булган тышкы күренеше белән генә бәйле түгел. Көзнең алтынлыгы, аның кадере һәм күркәмлеге барыннан да бигрәк көзге муллык белән билгеләнә. Сентябрьдә һәркемгә азык-төлекнең мул булуы хакында халык телендә, халык календарендә күп кенә гыйбарәләр бар. “Сентябрьдә син дә бер, мин дә бер” диләр. Әмма көзге байлыкны вакытында һәм югалтуларсыз җыеп алырга да кирәк.

Искечә беренче сентябрь әбиләр чуагы башланган вакыт буларак та билгеләнә. Ай дәвамында көннәр дә кыскара. Әбиләр чуагында җылы, коры көннәр торса да, кояшның җылысы инде сизелерлек кими. Ай азагында җил-яңгырлар ешая. Сентябрьдә табигатьне моңсулатып, күп кенә күчмә кошлар да бер-бер артлы җылы якларга сәфәргә чыгалар. Ай азакларында көзге күктә кыр казларының хушлашу авазлары ишетелә башлый. Бу инде көзнең җиңүе дигән сүз.